# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О Счетной палате Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
5 июня 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть); 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 83 (часть I); 2019, № 19 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 1 после слов «Бюджетным кодексом Российской Федерации,» дополнить словами «Федеральным законом от 7 февраля 2011 года № 6-ФЗ «Об общих принципах организации и деятельности контрольно-счетных органов субъектов Российской Федерации и муниципальных образований»,»;

2) статью 2 дополнить пунктом 7 следующего содержания:
«7) иные задачи в соответствии с федеральным законодательством и настоящим Законом.»;

3) часть 4 статьи 4 дополнить словами «в количестве, позволяющем обеспечить осуществление возложенных на нее полномочий, а также полномочий по внешнему муниципальному финансовому контролю, переданных на основании соглашений, заключенных с представительными органами муниципальных образований Республики Татарстан в порядке, установленном статьей $32^1$ настоящего Закона»;

4) пункт 2 части 5 статьи 5 после слов «внебюджетных фондов Республики Татарстан,» дополнить словом «ежеквартальные»;

5) в статье 13:

а) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Счетная палата осуществляет полномочия по внешнему муниципальному финансовому контролю в случае заключения с представительными органами муниципальных образований Республики Татарстан соглашений о передаче указанных полномочий в порядке, установленном статьей $32^1$ настоящего Закона.»;

б) пункт 1 части 2 после слов «государственных органов» дополнить словами «Республики Татарстан»;

в) дополнить частью 3 следующего содержания:

«3. Счетная палата в пределах компетенции осуществляет внешний государственный финансовый контроль также в отношении юридических лиц, индивидуальных предпринимателей, физических лиц, относящихся к объектам государственного финансового контроля в соответствии с бюджетным законодательством.»;

6) в части 4 статьи 16 слова «планов деятельности» заменить словами «годовых планов»;

7) часть 2 статьи 18 после слов «государственными органами» дополнить словами «Республики Татарстан», после слов «государственный финансовый контроль» дополнить словами «(далее также – проверяемые органы и организации)»;

8) в статье 21:

а) наименование дополнить словами «, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»;

б) часть 1 после слов «бюджета Республики Татарстан» дополнить словами «, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»;

в) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Счетная палата ежеквартально представляет Президенту Республики Татарстан, в Государственный Совет Республики Татарстан информацию о ходе исполнения бюджета Республики Татарстан, информацию о ходе исполнения бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан, в которых приводится анализ данных о доходах, расходах и об источниках финансирования дефицита бюджета Республики Татарстан, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан

в сравнении с утвержденными показателями законов о бюджете Республики Татарстан, бюджетах территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан.»;

9) в статье 22:

а) в части 1 второе предложение исключить;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Под ревизией понимается комплексная проверка деятельности объекта контроля, которая выражается в проведении контрольных действий по документальному и фактическому изучению законности всей совокупности совершенных финансовых и хозяйственных операций, достоверности и правильности их отражения в бюджетной (бухгалтерской) отчетности.»;

в) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Под проверкой понимается совершение контрольных действий по документальному и фактическому изучению законности отдельных финансовых и хозяйственных операций, достоверности бюджетного (бухгалтерского) учета и бюджетной (бухгалтерской) отчетности в отношении деятельности объекта контроля за определенный период.»;

г) часть 5 дополнить предложением следующего содержания: «Правоохранительные органы обязаны предоставлять Счетной палате информацию о ходе рассмотрения и принятых решениях по переданным Счетной палатой материалам.»;

10) статью 23 изложить в следующей редакции:

«Статья 23. **Контроль за состоянием государственного внутреннего и внешнего долга Республики Татарстан, бюджетных кредитов, предоставленных из бюджета Республики Татарстан**

Счетная палата осуществляет контроль за:

1) управлением и обслуживанием государственного внутреннего и внешнего долга Республики Татарстан;

2) законностью осуществления государственных внутренних и внешних заимствований Республики Татарстан;

3) соблюдением порядка предоставления и исполнения государственных гарантий Республики Татарстан;

4) соблюдением порядка предоставления бюджетных кредитов из бюджета Республики Татарстан;

5) эффективностью и соблюдением порядка размещения средств бюджета Республики Татарстан в банках и иных кредитных организациях.»;

11) в статье 26:

а) в части 1:

в пункте 1 слова «проект бюджета» заменить словами «проект закона о бюджете», после слов «дефицита бюджета Республики Татарстан» дополнить словами «, проекты законов о бюджетах территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»;

пункт 2 дополнить словами «, бюджетов территориальных государственных внебюджетных фондов Республики Татарстан»;

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) проекты законодательных и иных нормативных правовых актов (включая обоснованность финансово-экономических обоснований) по бюджетно-финансовым вопросам, вносимым на рассмотрение Государственного Совета Республики Татарстан;»;

дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5) проекты договоров и соглашений Республики Татарстан, влекущие правовые последствия для бюджета Республики Татарстан.»;

б) в пункте 1 части 2 слово «поручений» заменить словом «запросов»;

в) в части 4 слова «по вопросам ее ведения» заменить словами «по вопросам их ведения»;

12) дополнить статьей $32^1$ следующего содержания:

«Статья $32^1$. **Порядок заключения соглашений о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля**

1. Представительные органы муниципальных образований Республики Татарстан вправе обратиться в Счетную палату с предложением о заключении соглашений о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля при условии:

1) отсутствия в структуре органов местного самоуправления муниципального образования контрольно-счетного органа;

2) отсутствия заключенных представительным органом поселения, входящего в состав муниципального района, на очередной финансовый год соглашений о передаче контрольно-счетному органу муниципального района полномочий контрольно-счетного органа поселения по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля.

2. Обращение представительного органа муниципального образования Республики Татарстан о заключении соглашения о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля с очередного финансового года (далее – обращение о заключении соглашения) направляется в Счетную палату до 1 июля текущего финансового года.

3. По результатам рассмотрения обращения о заключении соглашения Счетная палата не позднее чем через 30 дней после его получения принимает одно из следующих решений:

1) решение о заключении соглашения о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля;

2) мотивированное решение об отказе от заключения такого соглашения.

4. Счетная палата в случае принятия решения о заключении соглашения о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля в течение 10 дней направляет в представительный орган муниципального образования Республики Татарстан проект соглашения в двух экземплярах для рассмотрения и подписания.

5. Представительный орган муниципального образования Республики Татарстан направляет подписанное соглашение в двух экземплярах в Счетную палату для подписания.

6. О заключенных с представительными органами муниципальных образований Республики Татарстан соглашениях о передаче Счетной палате полномочий по осуществлению внешнего муниципального финансового контроля Счетная палата уведомляет Государственный Совет Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
14 июня 2019 года
№ 46-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә “Россия Федерациясе Бюджет кодексына,” сүзләреннән соң “Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында” 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга,” сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:
“7) федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә башка бурычлар.”;

3) 4 статьяның 4 өлешендә “штатлар саны” сүзләреннән соң “аңа йөкләнгән вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Законның $32^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән төзелгән килешүләр нигезендә тапшырылган тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәрлек санда” сүзләрен өстәргә;

4) 5 статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында “мәгълүмат,” сүзеннән соң “квартал саен” сүзләрен өстәргә;

5) 13 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

“$1^1$. Хисап палатасы, әлеге Законның $32^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.”;

б) 2 өлешнең 1 пунктында “дәүләт хакимияте органнарына” сүзләре алдыннан “Татарстан Республикасы” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Хисап палатасы үз компетенциясе чикләрендә тышкы дәүләт финанс контролен шулай ук бюджет законнары нигезендә дәүләт финанс контроле объектларына караган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга карата да гамәлгә ашыра.”;

6) 16 статьяның 4 өлешендә “Хисап палатасы эшчәнлеге планнарын” сүзләрен “Хисап палатасының еллык планнарын” сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяның 2 өлешендә “үткәрелә торган” сүзләреннән соң “Татарстан Республикасы” сүзләрен өстәргә, “оешмалар” сүзеннән соң “(алга таба шулай ук – тикшерелә торган органнар һәм оешмалар)” сүзләрен өстәргә;

8) 21 статьяда:

а) исемендә “бюджеты” сүзеннән соң “, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары” сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлештә “бюджетын” сүзеннән соң “, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларын” сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Хисап палатасы квартал саен Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең барышы турында мәгълүмат, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлешенең барышы хакында мәгълүмат тапшыра, аларда, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары турындагы законнарда расланган күрсәткечләр белән чагыштырып, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары керемнәре, чыгымнары һәм аларның кытлыгын финанслау чыганаклары хакында белешмәләргә анализ ясала.”;

9) 22 статьяда:

а) 1 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Ревизия дигәндә контроль объекты эшчәнлеген комплексלы тикшерү аңлашыла, ул башкарылган бөтен финанс һәм хуҗалык операцияләре җыелмасының

законлылыгын, аларны бюджет (бухгалтерлык) хисаплылыгында күрсәтүнең дөреслеген һәм тәгәллеген документаль һәм фактта өйрәнү буенча тикшерү гамәлләрен үткәрүдән гыйбарәт.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Тикшерү дигәндә билгеле бер чорга контроль объекты эшчәнлегенә карата аерым финанс һәм хуҗалык операцияләренең законлылыгын, бюджет (бухгалтерлык) исәбенең һәм бюджет (бухгалтерлык) хисаплылыгының дөреслеген документаль һәм фактта өйрәнү буенча тикшерү гамәлләрен башкару аңлашыла.”;

г) 5 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Хокук саклау органнары Хисап палатасына ул тапшырган материалларны карау барышы турында һәм алар буенча кабул ителгән карарлар хакында мәгълүмат бирергә тиеш.”;

10) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“23 статья. **Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычының, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән бюджет кредитларының торышын тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора:

1) Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычына идарә итүне һәм хезмәт күрсәтүне;

2) Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашуларын башкаруның законлылыгын;

3) Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү һәм үтәү тәртибен үтәүне;

4) Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү тәртибен үтәүне;

5) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын банкларга һәм башка кредит оешмаларына урнаштыруның нәтиҗәлелеген һәм аларны урнаштыру тәртибен үтәүне.”;

11) 26 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта “бюджеты проектына” сүзләрен “бюджеты турында закон проектына” сүзләренә алмаштырырга, “, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары хакында законнар проектларына” сүзләрен өстәргә;

2 пунктта “бюджеты” сүзеннән соң “, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары” сүзләрен өстәргә;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелә торган бюджет-финанс мәсьәләләре буенча закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар проектларына (финанс-икътисадый нигезләүләрнең дәлиллелеген дә кертеп);”;

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

“5) Татарстан Республикасы бюджеты өчен хокукый нәтиҗәләргә китерә торган Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре проектларына.”;

б) 2 өлешнең 1 пунктында “йөкләмәләре” сүзен “гарызнамәләре” сүзенә алмаштырырга;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Хисап палатасы бәяләмәләрендә Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары үз карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул итә торган карарларга сәяси бәя бирү булмаска тиеш.”;

12) түбәндәге эчтәлекле $32^1$ статья өстәргә:

“$32^1$ статья. **Хисап палатасына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары Хисап палатасына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү хакындагы тәкъдим белән Хисап палатасына түбәндәге шартларда мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасында контроль-хисап органы булмаса;

2) муниципаль район составына керә торган җирлекнең вәкиллекле органы тарафыннан чираттагы финанс елына җирлекнең контроль-хисап органының тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районның контроль-хисап органына тапшыру турында төзелгән килешүләр булмаса.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен чираттагы финанс елыннан Хисап палатасына тапшыру турында килешү төзү хакында мөрәҗәгате (алга таба – килешү төзү хакында мөрәҗәгать) Хисап палатасына агымдагы финанс елының 1 июленә кадәр җибәрелә.

3. Килешү төзү хакында мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы аны алганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Хисап палатасына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзү хакында карар;

2) мондый килешү төзүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар.

4. Хисап палатасына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзү хакындагы карар кабул ителгән очракта, Хисап палатасы 10 көн эчендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге вәкиллекле органына карау һәм имзалау өчен ике нөсхәдә килешү проектын җибәрә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы имзаланган килешүне ике нөсхәдә Хисап палатасына имза кую өчен җибәрә.

6. Хисап палатасына тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләренең вәкиллекле органнары белән төзелгән килешүләр хакында Хисап палатасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 14 июнь
№ 46-ТРЗ